СОВЕТ ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422180

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 4-05-07; e-mail: Otar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

от 20.02. 2023 ел | № 3-22

ТР Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл жирлеге Советынын аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Советы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбәндәге карарларны үз көчен югалтты дип танырга:

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Советының 2005 елның 12 ноябрендәге «Җир налогы турында» 2-2 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Советының 2006 елның 1 августындагы «Отарка авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс турында» 6-10 номерлы карары.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлеге башлыгы И.И.Фазыловка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл жирлеге
Советы рәисе, җирлек башлыгы И.И.Фазылов

СОВЕТ ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ